КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 18 март г.Казань № 276

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы коллегиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2001 ел, 28 июль, 499 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы коллегиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2001 ел, 28 июль, 499 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 14 гыйнвар, 5 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «һәм аның составы» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы коллегиясе турындагы нигезләмәнең 1.5 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин